ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.09.2026 с.Старое Дрожжаное № 436

2027 елга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында туристлык-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

Россия Федерациясенең 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Мәгариф турында»гы Законының 99 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында»гы Федераль Законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы «Татарстан Республикасы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәни юнәлешле һәм өстәмә белем бирүнең күп профильле мәгариф оешмаларын финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карары һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2027 елга түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын;

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы өстәмә белем бирү оешмаларында инклюзив белем бирүне оештыру юлы белән сәламәтлек

мөмкинлекләре чикләнгән, инвалид укучылар өчен өстәмә гомуми үсеш программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарын;

балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының туристлык-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәни юнәлешле һәм балаларга өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга карата төзәтмәләр коэффициенты 0,95 күләмендә.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Финанс-бюджет палатасында әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар 2027 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.Ф. Заляловка йөкләргә.

Җитәкче Р.И. Мөхәммәтҗанов

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның "14" сентябрь
436 номерлы карары белән
расланган

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының туристлык-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәни юнәлешле һәм өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга

НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль-дислокация | Норматив чыгымнар, 1 укучыга елына сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать һәм эстетик | авыл җирлеге | 10 084 | 18 249 | 21 798 |
| Физкультура-спорт | авыл җирлеге | 9 984 | 18 149 | 21 698 |
| Техник иҗат | авыл җирлеге | 10 484 | 18 649 | 22 198 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | авыл җирлеге | 10 084 | 18 249 | 21 798 |
| Экологик-биологик | авыл җирлеге | 10 084 | 18 249 | 21 798 |
| Хәрби-патриотик | авыл җирлеге | 10 084 | 18 249 | 21 798 |
| Социаль-педагогик һәм икътисадый | авыл җирлеге | 9 884 | 18 049 | 21 598 |
| Табигый фәнни | авыл җирлеге | 10 084 | 18 249 | 21 798 |

Эшләр идарәчесе: Сабир Д.Р. Сабирзянова

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның "14" сентябрь 436 номерлы карары белән расланган

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы өстәмә белем бирү оешмаларында инклюзив белем бирүне оештыру юлы белән сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән, инвалид укучылар өчен өстәмә гомуми үсеш программаларын гамәлгә ашыруга

НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар, елга сумнар | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | терәк-хәрәкәт аппараты бозылулары, психик үсеше тоткарлануы, аутистик спектры бозылулары һәм үсешендә күп төрле авырлыклар булган бер укучыга | | | ишетү сәләте начар булган бер укучыга: саңгырауларга, начар ишетүчеләргә, соңрак саңгырауларга | | |
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары | укытуның беренче елы | укытуның икенче елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать һәм эстетик | авыл җирлеге | 20402 | 33581 | 37130 | 14439 | 24775 | 28324 |
| Физкультура-спорт | авыл җирлеге | 20302 | 33481 | 37030 | 14339 | 24675 | 28224 |
| Техник иҗат | авыл җирлеге | 20802 | 33981 | 37530 | 14839 | 25175 | 28724 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | авыл җирлеге | 20402 | 33581 | 37130 | 14439 | 24775 | 28324 |
| Экологик-биологик | авыл җирлеге | 20402 | 33581 | 37130 | 14439 | 24775 | 28324 |
| Хәрби-патриотик | авыл җирлеге | 20402 | 33581 | 37130 | 14439 | 24775 | 28324 |
| Социаль-педагогик һәм икътисадый | авыл җирлеге | 20202 | 33381 | 36930 | 14239 | 24575 | 28124 |
| Табигый фәнни | авыл җирлеге | 20402 | 33581 | 37130 | 14439 | 24775 | 28324 |

Эшләр идарәчесе: Д.Р. Сабирзянова